РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**МУСЛЮМОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУСЛЮМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**МӨСЛИМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

*№_05__* *«_28_»__май_ 2020 ел*

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 3 февралендәге 2 нче номерлы «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

1. Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 3 февралендәге 2 нче номерлы карары белән расланган адресларны бирү,үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 1.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«1.5. Әлеге Регламентта федераль мәгълүмат адреслар системасын эксплуатацияләү мәсьәләләрен регламентлаштыра торган федераль законнарда билгеләнгән күрсәткечләргә төгәл туры килә торган терминнар һәм билгеләмәләр, шулай ук адреслар турында дәүләт адреслы реестрында булган белешмәләрне куллану буенча мөнәсәбәтләр кулланыла.

«ТР Электрон Хөкүмәте» – Татарстан Республикасының Электрон документ әйләнеше системасы, Интернеттагы адресы: https://intra.tatar.ru

- Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзегенең ерактагы эш урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында»гы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 нче пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлегендә төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзегенең территориаль яктан аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә, муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы мөрәҗәгать аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 пункт).

Әлеге Регламентның гамәлдә булуы түбәндәге күчемсез милек объектларына кагыла: төзелеп беткән капиталь төзелеш объектлары (биналар, төзелеш, корылмалар), төзелеп бетмәгән объектлар һәм капиталь төзелеш максатларында бирелгән җир кишәрлекләре.

Әлеге Регламентның гамәлдә булуы түбәндәгеләргә кагылмый:

- ваклап сату челтәре объектлары (сәүдә һәм хезмәт күрсәтү өлкәсенең капиталь булмаган стационар һәм стационар булмаган объектлары);
- автомобиль транспорты тукталышлары (күпкатлы тукталышлардан тыш);
- металл һәм аерым торучы капиталь гаражлар (гараж-төзелеш кооперативларыннан тыш);
- югарыда күрсәтелгән объектларның гамәлдәге яисә урнаштырыла торган җир кишәрлекләре.»

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында muslumovo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын Татарстан Республикасы муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.З.Сахбетдинов**